**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылында гражданнар җыены карары**

18 ноябрь 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2021 елда Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукы булган балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 300 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Яңа Тинчәле авылында кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге чорда территорияне чаптыру (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), Беларусь тракторына асылмалы җиһазлар (чапкычлар) сатып алу, авылдагы хуҗасыз йортларны койма белән тоту эшләрен башкаруга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Яңа Тинчәле авыл җирлегенең Яңа Тинчәле авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Тинчәле авыл җирлеге башлыгы _________ Р.К. Мадышев

Халык җыены секретаре _________ Г.Ш. Хәсәнова